Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№38 (89)
28 ноябрь 2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

Федераль югары уку йортлары өчен электрон китапханә челтәрен булдыру мәсьәләсен нәтиҗәле хәл итү максаты белән, **22 НОЯБРЬ** көнне федераль университет вәкилләре катнашында **ВИДЕОКОНФЕРЕНЦ-ЭЛЕМТӘ ОЕШТЫРЫЛДЫ**. Алар «КОНТЕКСТУМ» лицензион-килешү технологиясен куллану мөмкинлекләре хакында фикер алышты.

• • • •

**25 НОЯБРЬДӘ** КФУның BP Exploration Operating Company Limited белән хезмәттәшлеге кысаларында **УНИВЕРСИТЕТКА** Россия икътисад мәктәбе ректоры **СИМЕОН ДЯНКОВ КИЛДЕ** Ул «БРИКС илләренең икътисади үсеше» дигән темага ачык лекция үткәрде. Гарвард университеты профессоры һәм атаклы болгар икътисадчысын тыңларга студентлар гына түгел, фәнни хезмәткәрләр дә килгән иде.

• • • •

**27-28 НОЯБРЬ** көннәрендә КФУның Идарә һәм территориаль үсеш институты базасында **«ИДЕЛ БУЕ ФЕДЕРАЛЬ ОКРУГЫНЫҢ ФӘННИ ЯШЬЛӘРЕ»** II Төбәкара яшьләр симпозиумы уза. Чараның төп максаты: Идел буе федераль округы югары уку йортларында белем алучы студентларның фәнни элемтәләрен киңәйтү.

• • • •

Кичә, **27 НОЯБРЬДӘ**, КФУның **ФӘЛСӘФӘ ФАКУЛЬТЕТЫ** конференц-залында Россия фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институтыннан тарих фәннәре докторы **ВИКТОР ШНИРЕЛЬМАННЫҢ АЧЫК ЛЕКЦИЯСЕ УЗДЫРЫЛДЫ**. Галим «Милләтчелек һәм үткәндәге образлар» темасына чыгыш ясады.

• • • •

**27 НОЯБРЬДӘ** КФУ ректоры **И.ГАФУРОВ** катнашында **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Контроль йөкләмәләр үтәлеше белән, гадәттәгечә, административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** таныштырды. Аннан соң икътисади һәм стратегик үсеш мәсьәләләре буенча проректор **М.САФИУЛЛИН** 2013-2020 еллар аралыгында дөньяда әйдәп бара торган фәнни белем бирү үзәкләре арасында КФУның конкурентлылыгын арттыру программасын гамәлгә ашыру өчен башкарыласы эшләр турында сөйләде. Тышкы элемтәләр департаменты директоры **А.КРЫЛОВ** «Айсек» халыкара яшьләр оешмасы белән үзара килешү төзергә әзерлек турында хәбәр итте. Оешманың максаты булып, яшьләрдә лидерлык һәм һөнәри потенциал тәрбияләү тора. «Айсек» дөньяның 124 илендәге 2400 университетны берләштерә. А.Крылов КФУ белән әлеге оешма арасында килешү төзелсә, нинди мөмкинлекләр ачылачагы турында сөйләде. Ректор киңәшчесе – иҗтимагый-мәгълүмати үзәк җитәкчесе **Ю.АЛАЕВ** КФУ сайтын үстерү буенча башкарылган эшләр нәтиҗәсе белән таныштырды. Әйтелгәннәрдән чыгып, ректор сайтның беренче битенә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимне хуплады. Универсиада авылы төшенчәсен башка сүз белән алыштырырга киңәш итте. Утырышта ректор И.Гафуров 17 ноябрьдә «Казан» Халыкара аэропортында авиаһәлакәттә һәлак булучыларга истәлек ташы куюга ярдәм йөзеннән университетта махсус фонд ачылуы турында да хәбәр итте. Акчаларны җыю белән уку йортының яшьләр сәясәте, социаль мәсьәләләр һәм физик тәрбия һәм спорт системасын үстерү департаменты шөгыльләнәчәк. Шулай ук иң яхшы таш эскизына конкурс игълан ителер дип көтелә.

• • • •

КФУның **ЯР ЧАЛЛЫ ИНСТИТУТЫ** Малайзиядәге иң алдынгы шәхси югары уку йортларының берсе **LINCOLN UNIVERSITY COLLEGE** белән үзара хезмәттәшлек турындагы **КИЛЕШҮ** төзеде. Документ студентлар һәм укытучылар, уку-укыту программалары һәм публикацияләр белән алмашу, уртак фәнни тикшеренүләр үткәрүне күз уңында тота.

• • • •

Шушы көннәрдә Санкт-Петербургта узган **V БӨТЕНРОССИЯ СТУДЕНТЛАР ФОРУМЫ УЗДЫ**. Атна дәвамында алар проектларын тәкъдир итте, эшлекле уеннарда һәм РФнең Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре белән утырышларда катнашты. Форумда КФУ данын Икътисад һәм финанслар институты магистрлары Т.Галимова һәм Т.Воробьева яклады. Алар тәкъдим иткән проектлар «Фәнни ачыш» номинациясендә лауреат булды.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*



# «Иҗат дәрте белән янам!»

«Һәр чорның үзенә лаеклылары – чор дәрәҗәсендә, үсеш-киләчәкне күз алдында тотып, алга әйди алырдай шәхесләр була», – дип язган Ш.Галиев. Бүген сезне таныштырырга теләүче яшьтәшебез Илнур Садыйков – нәкъ шундый шәхес. Аның яулаган үрләренең иге-чиге юк. Ә яулыйсылары алда әле! Дәвамы 4 биттә.

• Син һәм мин=БЕЗ!

# Яшьләр сәясәттә дә сынатмый

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

26 ноябрь көнне Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Актлар залында РФ конституциясенең 20 еллыгына багышланган «Политологик универсиада» конкурсы узды. Чара КФУның «Политсковородка» сәяси дискуссион студентлар клубы утырышы кысаларында оештырылды.

К студентларының дискуссион сәяси клубы ректор И.Гафуров инициативасы буенча 2012 елда оеша. Әлеге клуб җәмгыятьнең сәяси һәм социаль-иктисадый үсеше, яшьләр сәясәте һәм студент тормышының актуаль проблемалары турында фикер алышу мәйданы булып тора. «Минемчә, Россия конституциясенең юбилее календарьдагы дата гына түгел, ә тарихи һәм психологик чик», – диде клуб президенты Яна Сирюкова.

«Политологик универсиада» эшлекле уен форматында үтте. Чарада университетыбызның Юридик һәм Фәлсәфә факультетлары, Идарә һәм территориаль үсеш, Халыкара багланышлар, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтлары командалары катнашты. Командаларга һәм студентларга бәя бирү өчен, жюри составына Дәүләт думасы депутаты, «Бердәм Россия» фракциясе һәм белем бирү комитеты әгъзасы И.Гыйльметдинов, ТР Дәүләт Советының яшьләр җәмәгать палатасы рәисе Е.П.Ефимов, Дәүләт Думасы депутаты, КПРФ партиясе һәм мәдәният, фән, белем бирү, милли мәсьәләләр комитеты әгъзасы А.В.Прокофьев, Халыкара багланышлар, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты доценты В.Шагалов, Фәлсәфә факультеты профессоры О.Зазнаев чакырылган иде.

Беренче конкурс «Минем конституцион проект» дип аталды. Бу бәйгедә командаларга үзләрен төрле законнар, конституцион нормалар тудыручы ролендә татып карарга тәкъдим ителде. Һәр команда, яңа дәүләт уйлап чыгарып, аның конституциясе, андагы тормыш, хакимият тармаклары белән таныштырып, биремне креатив рәвештә башкарып чыкты. Мәсәлән, Фәлсәфә факультеты Лукоморье дәүләте, ә Юридик факультет Нарния иле белән таныштырып, үзләренең конституцион проектларын тәкъдим иттеләр. Беренче биремнең җиңүчеләре дип Фәлсәфә факультеты табылды.



Влад Михневский фотосы

Конкурсның икенче өлешендә һәр команда, үзенә бер партия сайлап, Россиядәге белем бирү системасына кертергә теләгән проектларын һәм программаларын тәкъдим итте. Бу бәйгедә экспертлар игътибарны фракция лидерының сөйләменә, ораторлык осталыгына, халык алдында ничек итеп чыгыш ясавына юнәлтте. И.Гыйльметдинов әйткәнчә, «Бердәм Россия» партиясен тәкъдим иткән Юридик факультет партиянең идеясен бик төгәл җиткерде. Шуңа күрә икенче өлештә юридик факультет беренче урынга чыкты. Бу бәйге кысаларында «Иң яхшы спикер» номинациясе буенча да җиңүчеләр билгеләнде. Иң уңышлысы дип Фәлсәфә факультетыннан ЛДПР партиясе спикеры Ольга Волчкова табылды. И.Гыйльметдинов аңа махсус бүләк тапшырды.

Чараның йомгаклау өлеше булган «Конституция белгечләре» бәйгесендә дә Юридик факультет алга чыкты һәм конкурсның абсолют җиңүчесе дип табылды. Фәлсәфә факультеты, юристлардан бераз гына калышып, 2 урынга лаек булды. 3 урын Халыкара багланышлар, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтына бирелде. Һәр командага да диплом һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

• Бездә кунак бар

Материалларны **Алинә САДЫЙКОВА** әзерләде

# Безне бар җирдә дә беләләр!

27 ноябрь көнне БДБ илләреннән килгән иҗади һәм җәмәгатьчелек оешмаларының яшь вәкилләре, журналистлар КФУга визит ясадылар. Алар 2 гасырдан артык тарихы булган уку йортыбыз, шәһәребез белән таныштылар.



Влад Михневский фотосы

К унакларны Тышкы элемтәләр буенча проректор Л.Латыйпов һәм ректор киңәшчесе – иҗтимагый-мәгълүмати үзәк җитәкчесе Ю.Алаев каршы алды һәм аларны кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

Очрашуның беренче өлешендә Л.Латыйпов Казан федераль университеты һәм аның Россиякүләм дәрәҗәдә тоткан урыны турында сөйләде:«Россиянең мәгариф системасы ике үзәк – Мәскәү һәм Санкт-Петербург университетлары, тугыз федераль университет һәм утыз фәнни-тикшеренү университетыннан гыйбарәт. Болар уку-укыту процессының төп нигезе булып торалар. Алар арасында безнең Казан университеты да бар».

Алга таба проректор «Казан университеты» дигән зур гаилә әгъзалары – уку йортыбызны тәмамлап, зур үрләр яулаган, танылган кешеләр турында сөйләде.

Татарстан ике дәүләт телле республика булганлыктан, кунаклар татар журналистикасы, аның үзенчәлеге белән кызыксындылар. «Милли тел дигәндә, татар теле күз алдында тотыла, гәрчә бу термин рус теленә карата да кулланыла ала. Республикабызда эш теле булып рус теле санала. Шулай да мәгълүматны, хис-кичерешләрне, татар телендә алучылар саны да бик күп, шуңа күрә бездә татар телендә газета-журналлар чыга, радиотелевидение эшли. Ә бу кадрларны әзерләү, нигездә, КФУның институтларына йөкләнгән», – дип билгеләде Ю.Алаев. Л.Латыйпов исә, бу сорауга сәяси халәт ноктасыннан чыгып җавап бирде: «Без, татарларның, менталитеты бик үзенчәлекле. Күпчелек вакытта журналистлар бу әйбер турында онытып җибәрәләр. Бездә мондый нечкәлекләрне күрә белергә һәм билгеле бер кагыйдәләрне сакларга өйрәтәләр».

Кунаклар барлык мәгълүматны игътибар белән тыңлап, әңгәмәдә катнашып утырдылар. Соңыннан кунакларның Казан университеты хакындагы фикерләре белән кызыксындык.

**Татьяна Чугаенко, «Первый деловой. Украина» телеканалы хезмәткәре:** «Миңа Казан бик ошады. Аның матурлыгы турында монда элегрәк килгән таныш дусларым сөйли иде. Бирегә килүем беренче тапкыр булса да, Университет, В.И.Ленин исемнәре аркылы шәһәрегез турында ишеткәнем бар иде. Л.Н.Толстойның тормышы да Казан университеты белән бәйле икәнен белү минем өчен зур яңалык булды».

**Владимир Зорик, Молдованың «Панорама» газетасы баш мөхәррире:** «Казанда һәм Казан университетында мин беренче тапкыр. Уку йортыгызның тарихы, ул әзерләп чыгарган галимнәрнең күплеге һәм аларның бөеклегенә исем китте. Бу очрашудан соң, Молдова белән КФУ арасында нык элемтәләр барлыкка килер һәм студентлар алмашы системасы да булдырылыр, дип ышанам».

• Белем баскычлары

# Нәтиҗәләр сөендерә

25-26 ноябрьдә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Академик хат һәм тикшеренү компетенцияләре» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды.

Ә легечара Еврокомиссия гранты исәбенә, «Инглиз теле укытучыларының белемнәрне бәяләү компетенцияләрен һәм гамәли күнекмәләрен формалаштыру» Темпус IV проекты кысаларында үткәрелде.

КФУның ФһМБ институты әлеге проектка 2011 елның октябрендә кушыла. Анда барлыгы 11 партнер-вуз катнаша һәм аны ике ел ярым эчендә гамәлгә ашыру каралган. Чит ил уку йортларыннан Саутгемптон университеты (Бөек Британия), Көньяк Богемия (Чехия республикасы) һәм Дрезд Техника университетлары (Германия) да бар.

Европа һәм Россия вузлары хезмәткәрләре белән берлектә, ФһМБ институты директоры Р.Жамалетдинов һәм контрастив лингвистика һәм лингводидактика кафедрасы профессорлары А.Садыйкова һәм М.Солнышкина әлеге яңа методик уку-укыту курсын булдыруда катнаштылар.

Проект нигезенә Европа уку йортлары тәҗрибәсе, кредит-модульле система һәм бу системаны Россиянең белем бирү процессына кертеп җибәрү салынган. Шуңа бәйле рәвештә, бу проект лингвистика буенча белемнәрне тикшерү таләпләренә туры килеп кенә калмыйча, Россия вузлары студентларының халыкара конкурентлылыгын һәм мобильлеген үстерүгә дә булышлык итә. «Безнең бүгенге фәнни дөньяда яңа юнәлешләр булдыру гына түгел, ә гамәлләребезне чит илләрдәге хезмәттәшләребез белән килештерү дә бик мөһим. Шуңа күрә Темпус кебек фәнни проектларда катнашу – ул безнең өчен бик зур әйбер», – дип искәртте М.Солнышкина. Бу курсның иң төп үзенчәлеге – аның Европа стандартларына туры килүе. Бүгенге көн таләпләренә мөрәҗәгать итсәк, ул лингвистика белгечләре буенча укучылар өчен генә түгел, башка төр һөнәр ияләре өчен дә файдалы һәм мөһим.

Студентларда бу курс зур кызыксыну уяткан: «Укучылар белән элемтәне күрәм: алар төпченәләр. Бу бик сөендерә. Проблемалар булмады түгел, әмма, тулаем алганда, без студентлардан һәм үзебездән дә канәгать», – дип әйтте М.Солнышкина.

Темпус проекты ярдәме белән, 25 ноябрь көнне ФһМБ институтында тел бәяләмәсе буенча ресурслы үзәк ачылды. Анда йөздән артык кеше катнашты. Катнашучылар академик хат турында күзаллау булдырдылар, интенсив курс тыңладылар һәм Мартин Хьюинс (Бөек Британия), Кэролин Вестбрук (Бөек Британия) һәм Хезер Меллоуларның (АКШ) мастер-классларын күзәтә алдылар.

Икенче көнне К.Вестбург лингвистик тәҗрибә үткәрде. Анда Л.Н.Толстой исемендәге рус һәм чит ил филологиясе бүлеге студентлары катнашты. Ике өлештән торган үзенчәлекле тәҗрибә бик күпләрдә кызыксыну уятты.

Конференциягә йомгак ясау рәвешендә, «Академик хат һәм заманча фәнни парадигма» исемле түгәрәк өстәл оештырылган иде. Анда фәнни мәкаләләр әзерләү методикасы һәм заманча юнәлешләр темаларына да тукталдылар.



Влад Михневский фотосы

Тарих сәхифәләре

# Ерак гасырлардан киләчәккә





Влад Михневский фотосы

Шушы көннәрдә Казан федераль университетының Алабуга институты үзенең 115 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.

Яңа форматта ул нибары ике ел гына эшләсә дә, аның тарихы бик кызыклы һәм ерак 1898 елга барып тоташа. Даннары бөтен Россиягә таралган Стахеевлар династиясе вәкиле Глафира Федоровна үзенең вафат булган ире истәлегенә уку йорты салдырырга була һәм моның өчен 200 мең сум акча бүлеп бирә. Әлеге уку йорты Епархиаль хатын-кыз училищесы статусында эшли башлый. Аның экспонатларга бай музее шул хакта дәлилле һәм образлы итеп сөйли.

1918 елда Епархиаль училище ябылып, аның урынына татар укытучылар семинариясе эшли башлый. 1920, елда Халык комиссариаты карары буенча, бирегә татар, урыс, мари һ.б. телләр буенча өчьеллык педагогик курслар эшли башлый. 1923 елның августында татар педкурслары Советында аның исемен Алабуга районы татар педагогик техникумына үзгәртергә дигән карар кабул ителә. 1936-1937 елларда педагогик техникум педагогик училищега әйләнә. Ике елдан соң, аның базасында тулы булмаган урта мәктәпләр өчен квалификацияле укытучылар әзерли торган укытучылар институты оеша. Анда студентларны барлыгы 4 факультетка: тарих, физика-математика, филология һәм табигый-географиягә бүләләр. 1952 елда, РСФСР Министрлар Советы карары нигезендә, ул Алабуга дәүләт педагогика институты, 2003 елда Алабуга дәүләт педагогика университеты статусын ала.

2011 елның 2 февраленнән уку йорты Казан федераль университетына кушыла һәм аның бер тармагы буларак эшли башлый. Ул үз эчендә генә кайнап, белгеч-педагоглар әзерләп чыгару белән генә шөгыльләнми, ә халык хуҗалыгында эшләрлек күп төрле белгечләр әзерли. Алабуга институтында белем алу юнәлешләре артып тора. Техник фәннәр, транспорт тармагы, шул ук вакытта гуманитар фәннәр буенча да яңача укытуга юнәлдерелгән зур эшләр алып барыла. Моңа карап, укытучылар әзерләүгә игътибар кимеми, ә киресенчә, арта һәм хәзер дә бу төп юнәлеш булып кала бирә.

Бүген институт карамагында 10 факультет, 20 кафедра, фәнни китапханә, 7 музей, агробиологик станция, 20дән артык лаборатория, спорт комплексы, 5 уку корпусы, 3 тулай торак бар.

2013 елның маенда Казан федераль һәм Санкт-Петербург дәүләт университетлары арасында фәнни-тикшеренү, уку һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлек һәм дуслык килешүе төзелде. Килешүгә символик рәвештә Алабуга институтында кул куелды, чөнки Бөек Ватан сугышы елларында нәкъ менә биредә СПбДУның эвакуацияләнгән филиалы урнашкан була.

Институтның күпсанлы уңышлары нигезендә, әлбәттә, тирән белемле, фәнни дәрәҗәләргә ия булган укытучыларның тырыш хезмәте ята. Коллективның үсеш офыклары, яуланасы үрләре алда, ә киләчәге – өметле.

Без – сәламәт студентлар!

# Оптимистик рухлы мехмат!

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

Н.И.Лобачевский ис. математика һәм механика институты – оптимистик рухта яши торган институтларның берсе. Фән һәм иҗат өлкәсе белән генә чикләнеп калмыйча, физик тәрбия дә институтыбызның әһәмиятле эшчәнлеге булып тора. Ә бу – студентларга һәм укытучыларга үз-үзләрен формада тоту һәм сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен менә дигән мөмкинлек!



Узган ел старт алган Спорт бәйрәме, быел да үз әһәмиятен югалтмыйча, 24 ноябрь көнне «Москва» спорт комплексында үтте. Чарада институтыбыз студентлары, укытучылары һәм Кытайдан килгән КНИТУ-КАИ студентлары да катнашты.

Әлеге Спорт бәйрәме сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, сәламәтлекне ныгыту, спорт традицияләрен дәвам итү максатыннан оештырыла.Чараны уздыру көне якшәмбегә туры килсә дә, уен мәйданы спорт сөюче студентлар белән шыгрым тулы иде. Сәламләү сүзе белән институтыбызның социаль һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары П.Великанов чыгыш ясады. «Сәламәтлек – һәммәбезнең дә алыштыргысыз байлыгы. Бу бәйрәм дә нәкъ менә сезнең өчен оештырыла. Монда килгәнсез икән, димәк, сез дөрес юлны сайлагансыз», – дип, катнашучыларга уңышлар теләде. Чыннан да, физик яктан да, рухи яктан да нык булган егетләр һәм кызлар тирәюньдәгеләрдә, һичшиксез, соклану һәм хөрмәт хисе уята. Академик Н.М.Амосов әйткәнчә, сәламәт булу өчен, үзеңнең көчеңне кызганмаска кирәк.

Бәйрәм күңелле музыкага зарядка ясау белән башланып китте. Ә ул, үз чиратында, һәммәбезгә көне буена җитәрлек энергия, күтәренке күңел көче өстәде. Күңелле стартлар, уен-көлке, җыр-бию, спорт уеннары, алкышлардан ел буена җитәрлек сүнмәс дәрт, позитив кәеф алдык. Уен мәйданының бер өлешендә баскетбол һәм волейбол, ә икенче өлешендә өстәл теннисы буенча ярышлар үтте. Узган елдан аермалы буларак, быелгы Спорт бәйрәменә башка уку йортлары студентлары – КНИТУ-КАИның Кытайдан килгән студентлары чакырылды. Аларның катнашуы бәйрәмне тулыландырып һәм көндәшлекне арттырып җибәрде. Аеруча баскетболда алар үз осталыкларын югары дәрәҗәдә күрсәтте. Моны исәпкә алсак, Спорт бәйрәме халыкара статуска ия, дисәм дә ялгыш булмас.

Бу көнне институтның һәр вәкиле рәхәтләнеп уйнады, күңел ачты. Спорт уеннары барышында һәр командадан җыйнаклык, бердәмлеге сизелеп торды. Программага кергән һәр спорт төрендә җиңүчеләр билгеләнде. Бүләкләр дә кызыктыра торган – медальләр, кубоклар, татлы призлар...

Спорт бәйрәме шуның белән тәмам. Традиция быел да, үз әһәмиятен югалтмыйча, һәммәбез күңеленә онытылмаслык шатлыклы мизгелләр бүләк итте. Чараны оештырганнары өчен, барлык студентлар исеменнән, институт җитәкчелегенә, укытучыларга, студентларга – һәммәсенә зур рәхмәтебезне җиткерәбез.

Дуслык дәресе



# Яңа Зеландиягә – җәяү!

**Дания ФАТЫЙХОВА,** хәбәрче

Шушы көннәрдә КФУның Экология һәм география институтының географик һәм экологик белем бирү бүлегендә 5 курс студентлары «Дөньядагы илләрнең таможня кагыйдәләре» исемле ачык дәрес күрсәттеләр.

Географик һәм экологик белем бирү теориясе һәм методикасы кафедрасы ассистенты Р.Фәрхуллин уздырган әлеге чарада тумышы белән Эфиопиядән булган Фундаменталь медицина һәм биология институтының 2 курс магистры Есуф Адем, Сьерра-Леонедан шул ук институт магистры Августин Бойма һәм Икътисад һәм финанслар институты магистры, алман Хеван Небреселасе да катнашты.

Әлеге дәрестән студентлар үзләре өчен бик күп яңа һәм кызыклы мәгълүмат алганнардыр дип исәплим. Мисал өчен, мөселман илләренә спиртлы эчемлекләр, тәмәке, дуңгыз ите һәм дуңгыз тиресеннән эшләнгән әйберләр алып бару тыела. Әлбәттә, бер илдә дә корал һәм наркотиклар алып кергән кешене аркасыннан сөймәячәкләр, шулай да Азия төбәкләрендә әлеге таможня кагыйдәләрен бозучыларны бик катгый җәза көтә: кайбер илләрдә җинаять өчен төрмә, ә Таиландта наркотиклар белән «эләгү» хәтта үлем җәзасына да китерергә мөмкин.

Африка илләрендә дә таможня кануннары бик кырыс икән. Аларны бозган очракта кешене җинаять җаваплылыгына да тартырга мөмкиннәр.

Күп илләрдә төрле үсемлек һәм хайваннарны читкә чыгару тыелган. Мисал өчен, Норвегиядән арктик төлке һәм бүре тиресеннән эшләнгән әйберләр; Доминикан республикасыннан орхидея һәм пальмалар; Кениядән сөяк, канат һәм тиредән ясалган сувенирлар алып чыгарга ярамый икән. Шунысын да әйтергә кирәк: кайбер илләрдә бик кызык һәм көлке булып тоелган кагыйдәләр дә очрый. Күпләрдә Сингапурга ни өчен сагыз алып керү һәм аны анда кулланырга ярамау зур сорау һәм аңлашылмаучанлык тудыра. Аның өчен зур штраф каралган. Яңа Зеландиягә велосипед һәм тәгәрмәчле башка хәрәкәт итү чараларын алып керергә ярамый. Бу ил вәкилләре шул рәвешле үзләренең гаҗәеп табигатьләрен сакларга тырышалар икән.

Дәрес өлешчә инглиз телендә узды. Шул уңайдан, студентлар «Таможня һәм паспорт контроле» темасына инглиз сөйләүлеге белән таныша һәм сүзлек запасын баета алдылар.

Чит ил студентлары Казан шәһәреннән бик канәгать булулары һәм Казан федераль университетында белем алулары белән горурлануларын әйттеләр. «Өй эшләрен генә күп бирәләр, әмма бу – студент тормышының аерылгысыз өлеше!» – дип тә өстәп куйдылар. Студентларыбызга укуда зур үрләр, ә ял итүчеләргә уңайлы һәм яхшы яллар телибез!

● Безнең тышлык

# «Иҗат дәрте белән янам!»

Әңгәмәдәш – **Кадрия ХӘСӘНОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм
социаль фәннәр институты

Илнур белән мин мәктәп елларыннан ук таныш. Ул Апас районы Морзалар авылыннан. Аның кебек актив, тырыш, булдырам дип йөри торган, иренмәс, житез һәм бар яктан да килгән егетләр сирәк. Уку дисеңме, җәмәгать эшчәнлегеме, иҗат, спорт – Илнур барысына да өлгерә. Милләтебезнең киләчәге әнә нинди кулларда! Сезне университетыбыз активисты Илнур Садыйков белән таныштырасым килә.

**Илнур, үзең белән таныштыруны мәктәп елларыннан башлап җибәр әле?**

- Мәктәптә укыганда, мин бөтен чараларда да бик теләп катнаштым. Ул спорт ярышы булсынмы, олимпиадалармы, сәләтлеләрне барлаучы фестиваль-конкурслар – һәммәсенә җаваплылык хисен тоеп, тырышып әзерләндем, эшләгән эшемнән тәм табып, рухланып йөрдем. Мәктәп командасы тупланганда, мине һәрвакыт капитан итеп билгелиләр иде. Монысы җаваплылыкны бермә-бер арттыра. Иҗатка килгәндә, нәфис сүз, җыр номинацияләре буенча республикакүләм «Йолдызлык» фестивале, «Дулкыннар» конкурсында катнашып, җиңүләр яулаган идем. Физика, химия, тарих фәннәрен тирәнтен өйрәндем. Республика күләмендә олимпиадаларда катнашып, әйбәт кенә нәтиҗәләргә дә ирештем.

**- Хәзерге уку юнәлешең физика һәм химиядән бик ерак бит?!**

- Әйе, әмма ул фәннәрнең укытучылары миндә кызыксыну уята алган. Без яши торган дөнья эчендәге икенче дөньяны ачу, өйрәнү кызык иде миңа. Башка фәннәрне дә яраттым. Мәктәпне гел «5»легә генә тәмамладым.

**- Алдагы соравымны дәвам иттереп, ничек икътисад өлкәсе буенча китәргә булдың соң?**

- Мәктәпне тәмамлаганда, алдымда өч юл иде: спорт юнәлеше, иҗади өлкә һәм, командага берләшеп, идарә итү эшчәнлеге. Уйладым-уйладым да, КФУда муниципаль дәүләт идарәсе белгечлеге алырга булдым.

**- Биредә мәктәптәге һәрьяклы актив эшчәнлегеңне дәвам иттердең инде?**

- Әйе, физкультура дәресендә төрле уеннарда мавыгып, кызыксынып катнашуымны күреп, факультетның спорт юнәлеше җитәкчелеге мине үз командасына алды. Студентларны төрле спорт уеннарына җәлеп итеп, уеннар оештырып, бергәләп эшли башладык. Универсиада авылына күчкәч, иҗтимагый тормышта тагын да активлашып киттем. Ул минем икенче йортыма әверелде. Бөтен тулай торак буенча спорт юнәлешен җитәклим. 7 мең студент өчен спорт уеннары, ярышлар оештырабыз, күңелле генә итеп сәламәтлек көне уза бездә.



■ 2012 елда Сочида узган «Студентлар марафоны» Бөтенроссия яшьләр форумында.

**- Универсиада уңаеннан оешкан, үзең җитәкләгән янгын куркынычсызлыгы отряды белән дә таныштырып үт әле?**

- Универсиада авылы мэры, спорт ярышларына әзерлек вакытында, безгә тулай торакта янгын куркынычсызлыгы буенча команда төзү идеясе белән мөрәҗәгать итте. Моның өчен тулай торакның һәр йортын яхшы белүче, Универсиада авылы белән якыннан таныш кешеләр кирәк иде. Шулай Янгынга каршы ирекле берләшмә оешты. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан оештырылган укуларда катнаштык, янгын сүндерүчеләр отряды белән махсус күнегүләр үттек. Һәркайсыбыз янгын куркынычсызлыгы буенча таныклыкка ия, махсус форма булдырылды. Үз техник базабыз бар. Спорт уеннары вакытында, без Универсиада авылында спортчылар белән бергә яшәдек, эшләдек, сакта тордык. Хәзер дә бу эш дәвам итә. Әлеге иҗтимагый оешмада барысы 56 кеше. Мин шуларның җитәкчесе. РФнең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан «Коткару эшләрен пропагандалау» өчен медале белән бүләкләндем.

**- Син бит әле төрле форумнарда, конкурсларда да катнашырга вакыт табасың!**

- Әйе, университетыбыз студентлары лидеры буларак, Россия күләмендә узган төрле форумнарга бик теләп йөрим, тәҗрибә туплыйм. Мәскәү, Екатеринбург һәм Сочида булып кайттык. Үз проектларым белән чыгыш ясадым, мактау грамоталары белән бүләкләндем. Иң мөһиме: эшмәкәрлек, оештыру һәм идарә эшчәнлеге буенча белемнәр тупладым, күп нәрсәгә өйрәндем. Беренче курста ук «Студентлар язы»нда катнашып, Муса Җәлилнең «Ромашка» шигырен сөйләдем. 2012 елда шушы ук бәйгедә Алия Фәйзуллина белән дуэт җырлап, «Автор җыры» номинациясендә беренче урынга лаек булдык.

**- Синең тагын да зуррак җиңүләрең бар бит әле?**

- Бөтен эшчәнлегемне тәкъдим иткәннән соң, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының сәләтле яшьләрне яклау буенча премиясе лауреаты булдым. Бу миңа алга таба бик зур этәргеч бирде. Тагын да тырышыбрак укырга, иҗтимагый тормышта катнашырга рухи әзерлек алдым. Шулай ук республикакүләм «Кадрлар резервы» проектында җиңү яуладым.

**- Үзеңне күп өлкәләрдә сынап караганнан соң, син киләчәк тормышыңны ничек күзаллыйсың инде?**

- Университетта алган белемемне дә, иҗади эшчәнлегемне дә, гомумән, бөтен кызыксынуымны бергә кушып эшләргә диген теләк туды. Бу, һичшиксез, эшмәкәрлек булырга тиеш иде. Хыялларымны һәм планнарымны тормышка ашыру ниятеннән, август аенда «Академия торжеств» дип аталган шәхси оешмамны ачып җибәрдем. Үзем кебек үк иҗат дәрте белән янган, яңалыкка омтылган һәм шул эшчәнлектән акча эшләргә әзер булган яшьтәшләремне җәлеп иттем. Үзем телгәнчә, оештыру эше белән дә шөгыльләнәм, иҗат итәм һәм ул – минем акча эшләү алымым да.

**- Синең уңышларыңа сөенәм, Илнур. Алга таба да зур җиңүләр генә юлдаш булсын!**

● Яшьлек-яңарыш

24-25 ноябрьдә «Сәләт» яшьләр үзәге сәләтлеләрне янә үзенә җыйды. Сәбәбе бер дигән: Рөстәм Бикмуллин исемендәге талантлы яшьләр фестивале. Исеме дә аның хәзер заманча, катнашучылар аны үзара «Бика Фест» дип йөртәләр.

# «Бика Фест» яңа офыклар ача!

**Илүзә ГАЙНЕТДИНОВА,** Гаммәви
коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Фестивальнең әзерлекле булуы, һәр детале алдан уйланылганлыгы әллә кайдан күренеп тора. Катнашучылар саны да елдан-ел арта. Быел аларның саны 120гә җиткән. Чарага әзерлек чорында оештыручыларның йокламаган төннәре дә шактый булгандыр. Элек «Бика Фест» гади генә бер бәйге иде. Ул ничек колачларын бу дәрәҗәдә киң җәя алды соң? «Монда бернинди дә сер юк. Төгәл куелган максатлар, күңелеңне яраткан эшеңә бирү һәм, әлбәттә, тырышлык – менә ул уңыш формуласы!» – дип белдерде бу уңайдан фестивальнең арт-директоры Айназ Гайниева. «Бика Фест» ике көн дәвамында барды. 24 ноябрь – сайлап алу туры көне – бик тыгыз һәм дулкынландыргыч мизгелләргә бай булды. Чараның сайлап алу туры «Регина» кунакханәсендә үтте. Катнашучылар жюри әгъзаларына үзләренең талантларын, осталыкларын булдыра алганча югары дәрәҗәдә күрсәтергә тырыштылар. Кайберләре берничә номинациядә чыгыш ясарга өлгерде хәтта. Сайлап алу туры тәмамлангач, жюри финалистларны игълан итте. Аннары Yummy music компаниясе продюсеры Алмаз Сәмигуллин һәм шушы компания резиденты – җырчы Гөлназ Батталова катнашучылар белән иҗат, җырчылар тормышы турында әңгәмә кордылар. Алар яшьләргә бик файдалы киңәшләрен җиткерде. Аннан теләүчеләр гитарага җырлап, аралашып утырды. Фестиваль яшьләрне берләштерә һәм дуслаштыра торган чарага әверелде. 25 ноябрь көнне исә, финалга үтүчеләрнең чыгышларыннан торган гала-концерт гөрләп узды. Яшь талантларның күплегенә сөенеп утырдык.

«Барысы да алда әле, без бит – яшьләр. Бу проектны беренче тапкыр башкаруыбыз. Ничек кенә булмасын, «Бика Фест» елдан-ел үсәргә тиеш. Мондый чаралар иҗат белән янучыларга яңа офыклар ача!» – дип белдерде Айназ Гайниева «Бика Фест»ның киләчәге хакында.

● Халыкара әниләр көне

# Әнидән дә газиз кем бар?

**Адилә ГЫЙЛАЕВА,** Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты



Кем генә булмыйк без, нинди генә югары дәрәҗәләргә ирешмик, иң беренче чиратта, һәрберебез дә бу дөньяга безне бүләк иткән Әниләргә бурычлы.

Әнкәй... Бу дөньяда синнән дә якын, газиз, кадерле кеше юклыгын тулай торакта, студент тормышы белән «кайнап» яши башлагач, тагын да тирәнрәк төшендем.

Синең өчен янып-көеп, кызым ач-ялангач түгелме, кайларда йөри, дип ут йотып торучы тагын кем бар бу дөньяда? «Кызым, тор инде, мәктәпкә соңга каласың», – дип иркәләп уятулары, дәрестән кайтуга тәмле ашлар пешереп көтеп алулары еш искә төшә шул монда.

Назлы сүзләреңне, җылы ашларыңны, күркәм йөзеңне сагынып кайтам, әнием!

Дөньяга килеп, күзләрем ачылуга, синең нурлы йөзеңне күргәнмен, җылы кулларыңны тойганмын, колагым таныш тавышыңны ишеткән. Минем өчен дөньяда синнән дә газиз беркем юк. Син, әнием, без, өч балага, сабый вакытта, төн йокыларыңны калдырып, бишек җыры көйләдең. Энем белән сеңлемне ничек итеп кулыңда тирбәтеп йөрүең әле дә күз алдымда.

Бер хәдистә: «Анаң, анаң, аннары анаң, аннан соң гына атаң», – диелә. Бу сүзләрнең олуг мәгънәсе әһәмиятен беркайчан да югалтмаячак. Бөтен дөньяда Ана көнен зурлап билгеләп үтү – бик куанычлы хәл! Ләкин без аларны бу көнне генә түгел, ә һәрвкыт зурларга, хөрмәтләргә тиеш.

Мин бик бәхетле, чөнки мине һәрвакыт җылы кочагына алучы әнием бар. Җирдә ятимнәр булмасын, һәр бала әнисенең җылы кочагын тоеп яшәсен!

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.